Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советы

КАРАР

«23» ноябрь 2021 ел № 51

## Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре «Шикәрчеләр» микрорайоны территориясендә яшәүчеләр өчен үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2021 елның 4 декабрендә 12 сәгать 00 минутта Нурлат ш., Завод ур., 17а йорт адресы буенча Халыклар дуслыгы йорты бинасына төп керү урыны янында, «Шикәрчеләр» микрорайоны территориясендә Маяковский (барлык йортлар), Карбышев (19-32 нче йортлар) урамнарында урнашкан шәхси торак йортларда яшәүчеләр өчен генә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыруны билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә, аңа сайлау хокукына ия территориядә яшәүчеләрнең исемлекләрен, гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә, халыкка массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә, җыенны үткәрү өчен бина бирергә һәм җыенны үткәрү датасына 5 көннән дә соңга калмыйча Башкарма комитетта гражданнар җыенын кararга чыгарыла торган материаллар белән таныштыру мөмкинлеген бирергә, Җыенга чыгарыла торган мәсьәлә буенча кирәкле һәм махсус белешмәләргә ия булган оешма вәкилләренең һәм затларның җыелышта катнашуын тәэмин итәргә, җыен беркетмәсен рәсмиләштерергә.

3. Халык җыенында чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2022 елда Татарстан Республикасының Нурлат шәһәрендәге Маяковский (барлык йортлар), Карбышев (19-32 нче йортлар) урамнарында урнашкан шәхси торак йортлар гына кергән «Шикәрчеләр» микрорайоны территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

Татарстан Республикасы Нурлат шәһәрендә Маяковский (барлык йортлар), Карбышев (19-32 номерлы йортлар) урамнарында юынтык суларны агызу челтәрләрен төзүгә әзерләнә торган проект-смета документациясен һәм дәүләт экспертизасын уздыруга әзерләнүче документларны хәзерләү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Нурлат шәһәре Советы Рәисе А.С. Әхмәтшин